ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

29 09 2023 г. № 932

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 20 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыр йөкле һәм (яки) эре габаритлы транспорт чараларының автомобиль юлларында хәрәкәт итүгә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 985 номерлы карарын;

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китергән зыянның күләмен билгеләү турында» 2022 елның 27 сентябрендәге 663 номерлы карарын.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче　　　　　　　　Р.Ф. Булатов